| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 ноябрь 2013 Казан ш. 10-52/кс №лы

***Эчүгә яраклы суга бүлүгә тарифның билгеләнүе турында***

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 07 декабрь 2011 416-ФЗ №лы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендәге дәүләт тарифларның көйләнүе турында» 13 май 2013 406№лы карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә гамәлдәге тарифларның максималь индексларның билгеләнүе турында» 21 октябрь 2013 192-э/3 №лы әмере, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15 июнь 2010 468 №лы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты буенча БОЕРА:

1. Әлеге карарның кушымтасы буенча календарь бүленеше буенча суык су белән тәэмин итүче һәм су бүлүче оешмаларның кулланучыларга тәэмин иткән эчүгә яраклы суга һәм су бүлүгә тарифларны билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1нче пунктында билгеләнгән тарифлар 01 январь 2014 нче елдан башлап 31 декабрь 2014 елына хәтле гамәлдә булачак.

3. Әлеге карарның кушымтасында күрсәтелгән су белән тәэмин итүче һәм су бүлүче оешмаларга Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 17 январь 2013 6 №лы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендәге мәгълүматны ачу стандартлары буенча ирекле ирешүгә тиешле мәгълүматны чираттагы көйләү периодына тарифларның билгеләнүе турында карарның алыну көненнән башлап иң соң 30 календарь көне эчендә ачырга.

4. 01 январь 2014 елыннан башлап түбәндәгеләрне гамәлдән чыкан дип танырга:

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Эчүгә яраклы суга һәм су бүлүгә тарифларның билгеләнүе турында» 12 апрель 2013 10-13/кс №лы карарының 1 кушымтасының 1 пункты, 3 кушымтасы;

5. Әлеге карар рәсми рәвештә нәшер ителү көненнән сон ун көн эчендә көченә керә.

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 29 ноябрь 2013 10-52/кс №лы карарының Кушымтасы

## Суык су белән тәэмин итүче һәм су бүлүче оешмаларның кулланучыларга тәэмин иткән эчүгә яраклы суга һәм су бүлүгә тарифлар

| № п/п | Муниципаль оешманың, суык су белән тәэмин итүче һәм су бүлүче оешмаларның атамалары | Тариф на Эчәргә яраклы суга тариф, (бер ставкалы), сум/куб.м | | Су бүлүгә тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | Юынтык суларның ташуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 гыйнварь 2014 тән 30 июнь 2014 хәтле | 1 июль 2014 тән 31 декабрь 2014 хәтле | 1 гыйнварь 2014 тән 30 июнь 2014 хәтле | 1 июль 2014 тән 31 декабрь 2014 хәтле | 1 гыйнварь 2014 тән 30 июнь 2014 хәтле | 1 июль 2014 тән 31 декабрь 2014 хәтле |
| | Алексеевск муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | «Алексеевскводоканал» ААҖ* | 23,57 | 24,05 | 30,42 | 31,05 | | |
| 2 | «Водоканал» ҖЧҖ* | 19,32 | 20,14 | | | | |
| | Яшел Үзән муниципаль районы | | | | | | |
| 3 | «МПП Комэнерго» ҖЧҖ* | 20,57 | 20,57 | 9,65 | 10,15 | | |
| | Менделеевск муниципаль районы | | | | | | |
| 4 | ААҖ «Л.Я.Карпов исемендәге химия заводы» (тарифка НДС керми) | | | | | 14,75 | 15,71 |
| | Саба муниципаль районы | | | | | | |
| 5 | «Саба МПП ЖКХ» ААҖ* | 22,33 | 22,33 | 44,04 | 44,50 | | |
| | Казан шәһәре | | | | | | |
| 6 | Шәхси эшмәкәр Шаматов Индус Кашипович* | | | | | 9,46 | 9,46 |

(*) - оешма салым йөкләмәнең гадиләштерелгән системасын куллана

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының карарларының алыну
оештыру, тикшерү һәм алып бару бүлеге